РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.03.2022

КАРАР
№ 215-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны казначылык белән тәэмин итү очракларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары тарафыннан акчаларны казначылык белән тәэмин итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» (алга таба - 2155 номерлы Карар) 2021 елның 1 декабрендәге 2155 номерлы карары , Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.26 статьясы (алга таба - РФ БК 242.26 статья) нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны казначылык белән тәэмин итү 2155 номерлы карар һәм РФ БК 242.26 статьясы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының (муниципаль берәмлекләрнең) финанс органнары тарафыннан акчаларны казначылык белән тәэмин итү тәртибенә карата гомуми таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

1.1. 50 миллион сумнан кимрәк суммада төзелә торган муниципаль контрактлар буенча;

1.2. муниципаль бюджет яисә автоном учреждениеләр тарафыннан 50 миллион сумнан кимрәк суммада төзелә торган контрактлар (килешүләр) буенча, аларның исәп-хисаплары Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының финанс органында ачылган, күрсәтелгән учреждениеләргә Россия Федерациясе законнары нигезендә керә торган акчалар хисабына.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, икътисад бүлеге начальнигы М. М. Баһмановка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Ишниязов